СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 4-38 от «13» декабря 2024 г.

2025 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2025 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә..

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе В.И.Никитин

000154

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының
_13.12._ 2024 ел , № 4-38
карары белән
расланды

2025 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

Глава 1. Основные направления и задачи реализации политики в сфере приватизации муниципального имущества

Глава 1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары

2025 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга салучы башка норматив-хокукый актлар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 октябрендә 10-35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында Нигезләмә нигезендә эшләнгән.

Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның төп бурычы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерү.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру программасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- тулаем алганда, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисады һәм аерым хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына муниципаль милекне хосусыйлаштырудан планлаштырылган барлык керемнәрнең дә үз вакытында һәм тулаем керүе;

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан кергән акчалар хисабына җирле бюджетны тулыландыру;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;

2025 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала.

Ел дәвамында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкендә булган хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга фараз планына кертелә.

## 2 бүлек. 2025 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль милек объекты исемлеге һәм характеристикасы

### 1.Муниципаль милек:

| № п/п | исеме | Урнашу адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Гамәлгә ашыруның күздә тотылган вакыты | Кем баласында тора |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | FIAT Albea VINXU3178000CZ147142 дәүләт номеры: О754ХУ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 1 квартал 2025 ел | ТР Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының “Район мәдәният йорты”МБУ |
| 2 | Фиат Дукато VINZ76244000ASO119 93 дәүләт номеры: М942ТТ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 1 квартал 2025 ел | ТР Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының “Район мәдәният йорты”МБУ |
| 3 | 16:26:340128:499 | ТР, Мамадыш | ачык | 2 квартал | ТР Мамадыш |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кадастр номерлы торак булмаган бина | муниципаль районы, Мамадыш ш. Совет ур. 11/6 й. №21бина | аукцион | 22025 ел | муниципаль районы |
| 4 | FORD EXPLOER Z6FBXXESWBFC27090 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й | ачык аукцион | 2 квартал 2025 ел | ТР Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 5 | Шевроле НИВА212300-55 VIN X9L212300J0664401 дәүләт номеры В827АА 716 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й | ачык аукцион | 3 квартал 2025 ел | ТР Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән АЖ БК |
| 6 | Шевроле НИВА212300-55 VIN X9L212300K0676989 дәүләт номеры В414РЕ | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й | ачык аукцион | 3 квартал 2025 ел | ТР Мамадыш муниципаль районы Соколка АЖ БК |
| 7 | Шевроле НИВА212300-55 VIN X9L212300K0676992 дәүләт номеры С129УМ | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й | ачык аукцион | 3 квартал 2025 ел | ТР Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт АЖ БК |

Хосусыйлаштыру программасын гамәлгә ашыру sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында аукцион уздыру юлы белән, шул исәптән хосусыйлаштыру ысулларын һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнгән башлангыч бәясен үз эченә алып, гамәлгә ашырылачак.

Әлеге программада каралган хосусыйлаштыру шартлары турында Карар кабул итү муниципаль милекне хосусыйлаштыру максатларын һәм бурычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.